СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

18.09.23г № 36/1

На №_________от_____________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2023 елның 25 августындагы халык тыңлаулары беркетмәсе, Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2023 елның 25 августындагы халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 20 февралендәге 30/6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев